ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Казан шәһәре № 6-80/тп

«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газдан файдалану җайланмасын технологик ялгау өчен 2020 елга түләү билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бәяләрен, аны транспортлаштыру хезмәтләренә тарифларны һәм газдан файдалану җайланмасын Россия Федерациясе территориясендә газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Монополиягә каршы федераль хезмәтенең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм (яки) аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1151/18 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә газ куллана торган җиһазларны «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга түләү күләмен билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү күләме 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Газ куллана торган җиһазларны «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга икътисади нигезләнгән түләү күләме 489,88 мең сум тәшкил итә.

4. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категорияләрен тоташтырудан төшеп калучы керемнәрен 3194,4 мең сум күләмендә билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
13.11.2019 № 6-80/тп карарына кушымта

# Газ кулланучыны җайланманы «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтыруга 2020 елга түләү күләме

| Номеры | Мөрәҗәгать итүчеләрнең категориясе | Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге чикләреннән газ бүлү челтәрләренә кадәрге аралык | Технологик тоташтыру өчен түләү күләме, сум. | |
|---|---|---|---|---|
| | | | НДС исәпкә алмыйча | НДС исәпкә алып<*> |
| 1. | Сәгатенә 5 куб. метрдан артмаган максималь газ сарыфы белән, мөрәҗәгать итүченең әлеге ноктага элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җайланмасының газ сарыфын исәпкә алып (газдан эшкуарлык (коммерциячел) эшчәнлек максатларында файдалану нияте булмаган, башка мөрәҗәгать итүчеләр өчен), туры линия буенча үлчәнә торган эш басымы иң күбе 0,3 МПа булган проекты белән газдан файдалану җайланмасының заявка тапшырылган газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәрге аралык 200 метрдан артмау һәм чараларның бары тик газүткәргечләр – кертү җайланмасы (газ редукцияләү пунктларын урнаштырмыйча һәм траншеядән башка газүткәргеч салу чараларын үтәү зарурлыгыннан башка) төзүнең генә күздә тотылу шарты белән. | 10 м кадәр (шуннан артмый) | 22 720,14 | 27 264,17 |
| | | 10 м озынрак, 20 м кадәр (шуннан артмый) | 34 080,21 | 40 896,25 |
| | | 20 м озынрак | 56 800,35 | 68 160,42 |
| 2. | Сәгатенә 15 куб. метрдан артмаган максималь газ сарыфы белән, мөрәҗәгать итүченең әлеге ноктага элегрәк тоташтырылган газдан файдалану җайланмасының газ сарыфын исәпкә алып (газдан эшкуарлык (коммерциячел) эшчәнлек максатларында | 200 м кадәр (шуннан артмый) | 56 800,35 | 68 160,42 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | файдалану нияте булган мөрәҗәгать итүчеләр өчен), туры линия буенча үлчәнә торган эш басымы иң күбе 0,3 МПа булган проекты белән газдан файдалану җайланмасының заявка тапшырылган газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә кадәрге аралык 200 метрдан артмау һәм чараларның бары тик газүткәргечләр – кертү җайланмасы (газ редукцияләү пунктларын урнаштырмыйча һәм траншеясез ысул белән газүткәргеч салу чараларын башкару зарурлыгыннан башка) төзүнең генә күздә тотылу шарты белән. | | | |

<*> Мөрәҗәгать итүчеләр – физик зат булган очракларда

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге